ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР ______________

с. Верхний Услон

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 05.04.2013 №426 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 05.04.2013 № 426 карарына үзгәрешләр кертергә.
2. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2013 елның 05 апрелендәге 426 номерлы карарының 1 нче кушымтасы текстын әлеге Карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында «Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 05.04.2013 №426 карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2013 елның 5 сентябрендәге 1312 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды
О.А.Сельская

Татарстан Республикасы Югары
Ослан муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
№_________ карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| № т/б | Хезмәтнең атамасы |
|---|---|
| Җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләр буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү | |
| 1. | Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Никахны өзүне дәүләт теркәве |
| 3. | Тууны дәүләт теркәве |
| 4. | Уллыкка (кызлыкка) алуны дәүләт теркәвенә алу |
| 5. | Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәве |
| 6. | Исем үзгәрешен дәүләт теркәвенә алу |
| 7. | Үлемне дәүләт теркәвенә алу |
| 8. | Гражданлык хәле акты язмасына төзәтмәләр яисә үзгәрешләр кертү |
| 9. | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар һәм граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу фактын раслый торган башка документлар (белешмәләр) бирү |
| 10. | Гражданлык хәле актын яңадан торгызу (гамәлдән чыгару) |
| 11. | Балалар тәрбиясендә булганнарны стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль учреждениеләргә җибәрү турында карарлар бирү. |
| 12. | Суд тәртибендә хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләп кую. |
| 13. | Гомерлеккә якын кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү. |
| 14. | Балигъ булган хокуктан файдалануга сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү. |
| 15. | Опекунга үз карамагындагы кешенең фатирын наемга тапшыруга рөхсәт бирү. |
| 16. | Тәрбияләнүчеләрнең мөлкәте белән алыш-биреш кылуга рөхсәт бирү. |
| 17. | Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга яшәү урыны буенча теркәлү исәбен алып баруга рөхсәт бирү. |
| 18. | Опекунга яисә попечительгә муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты карамагындагы кешенең нәсел хокукларына керүгә рөхсәт бирү. |
| 19. | Опекунга яисә попечительгә муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты карамагындагы счетның саклык счетын файдалануга рөхсәт бирү. |
| 20. | Суд тәртибендә социаль учреждениедә стационар хезмәт күрсәтүдә булган хокукка сәләтсез дип танылган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләсенә вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү. |
| 21. | Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу. |
| 22. | Торак сатып алуга кредит акчаларыннан файдаланып алдан рөхсәт бирү һәм аны, балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру. |
| 23. | Балигъ булмаган баланы эмансипацияләү мөмкинлеге турында карар кабул итү (балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү). |

| | |
|---|---|
| 24. | Балигъ булмаганның акчалата кертеме алу өчен законлы вәкилгә рөхсәт бирү. |
| 25. | Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яисә) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү. |
| 26. | Балигъ булмаганнарның күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү |
| 27. | Балигъ булмаган (алар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү. |
| 28. | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү. |
| 29. | Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, гражданнарга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү. |
| 30. | Балигъ булмаган яшьтәге күчемсез милекне читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү. |
| 31. | Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую. |
| 32. | Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта сакланган архив документларын муниципаль архивның уку залында эшләү өчен куллanучыга бирү. |
| 33. | Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация. |
| 34. | Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документларының күчермәләрен бирү. |
| 35. | Архив эшендә методик һәм практик ярдәм дәүләт милкендәге юридик затларга эш башкаруда документлар оештыру буенча дәүләт формасы булган юридик затларга күрсәтү. |
| | Муниципаль хезмәтләр |
| 1. | Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү |
| 2. | Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү |
| 3. | Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне рәсмиләштерү (беркетү) |
| 4. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү. |
| 5. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү |
| 6. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү. |
| 7. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату. |
| 8. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү. |
| 9. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген, җир кишәрлегендә урнашкан |

| | |
|---|---|
| | биналар, корылмалар милеккә яисә арендага бирү. |
| 10. | Аукцион формасында уздырыла торган торгларда муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага бирү. |
| 11. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә уздырыла торган сату-алуларда сату юлы белән милек итеп бирү. |
| 12. | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү. |
| 13. | Муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү. |
| 14. | Крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына муниципаль милектәге җир кишәрлеген милек буларак (арендага) бирү. |
| 15. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү. |
| 16. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү. |
| 17. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнарга милек буларак (арендага) бирү. |
| 18. | Хосусый яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) икенчесенә күчерү турында карар кабул итү. |
| 19. | Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү. |
| 20. | Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү. |
| 21. | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү. |
| 22. | Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү. |
| 23. | Муниципаль милек булган җир кишәрлекләрендә хәзинә эзләүгә рөхсәт бирү. |
| 24. | Муниципаль преференцияләр бирү. |
| 25. | Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую. |
| 26. | Муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү. |
| 27. | Казнаның муниципаль мөлкәтен арендага бирү. |
| 28. | Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут билгеләү турында килешү төзү |
| 29. | Элек хосусыйлаштырылган торак биналарын муниципаль милеккә кабул итү. |
| 30. | Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү. |
| 31. | Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалану төрен үзгәртү. |
| 32. | Җир кишәрлеген гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре әгъзасы булган гражданга түләүсез бирү. |
| 33. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль мөлкәт тапшыру. |

| | |
|---|---|
| 34. | Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бирү. |
| 35. | Торглар үткәрмичә муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыру. |
| 36. | Мондый шартнамәне төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү. |
| 37. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга индивидуаль торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү |
| 38. | Муниципаль мөлкәтне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү. |
| 39. | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү. |
| 40. | Авыр йөкләрне, эре габаритлы йөкләрне муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә узучы маршрутлар буенча автомобиль йөртүгә рөхсәт бирү. |
| 41. | Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү. |
| 42. | Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле итеп тану. |
| 43. | Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү. |
| 44. | Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү. |
| 45. | Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм аларга тиңләштерелгән затларга радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга дәүләт торак сертификатын исәпкә алу һәм бирү. |
| 46. | Гражданга муниципаль милектәге торак урынны социаль наем шартнамәсе буенча бирү. |
| 47. | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидия бүлеп бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү. |
| 48. | Торак урыннарына мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую. |
| 49. | «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык исәпкә кую һәм бирү. |
| 50. | Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләренә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү. |
| 51. | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую. |
| 52. | Объектның архитектура-шәһәр төзелеше күренешен килештерү турында карар бирү. |
| 53. | Җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү. |
| 54. | Инженер-геологик тикшеренүләр җитештерүгә рөхсәт бирү. |
| 55. | Җирлекнең (шәһәр округының) генераль планыннан өземтә бирү. |

| | |
|---|---|
| 56. | Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар кабул итү. |
| 57. | Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү. |
| 58. | Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү. |
| 59. | Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзелешен килештерү. |
| 60. | Төзелеш тәмамланмаган объектларны файдалануга рөхсәт бирү. |
| 61. | Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләре схемасын раслау. |
| 62. | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү. |
| 63. | Җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү. |
| 64. | Ана (гаилә) капиталын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү. |
| 65. | Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү хезмәтләре күрсәтү. |
| 66. | Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү. |
| 67. | Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү. |
| 68. | Юридик затларга архивлар эшендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру. |
| 69. | Ликвидацияләнә торган оешмаларның шәхси составы буенча документларны муниципаль архивка саклау өчен кабул итү. |
| 70. | Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга архив документларын бирү |
| 71. | Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация. |
| 72. | Адресларны үзләштерү, үзгәртү, гамәлдән чыгару. |
| 73. | Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау. |
| 74. | Васыять кәгазе һәм ышанычнамә таныклыгы. |
| 75. | Белешмә (өземтә) бирү. |
| 76. | Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү. |
| 77. | Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү. |

Башкарма комитетның эшләр идарәчесе    А.К. Минһаҗева